Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 29-2 21.09.2026ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының 2022 елның 10 октябрендәге 52-1 номерлы «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт хакимияте бердәм системасы кысаларында җирле үзидарәне оештыруның гомуми нигезләре турында"гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының 2022 елның 10 октябрендәге 52-1 номерлы «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (2023 елның 20 февралендәге 62-1 номерлы, 2026 елның 03 сентябрендәге 28-1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3-нче маддәнең 1-нче өлешендәге 11-нче пунктта «бу Федераль закон» сүзләре «"Дәүләт хакимияте бердәм системасы кысаларында җирле үзидарәне оештыруның гомуми нигезләре турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 17-нче маддәнең 1-нче өлешендәге 7-нче пункт түбәндәге редакциядә бәян итергә:

"7) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары, шулай ук муниципаль норматив актлар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә, шулай ук йөкләмәләрне башкарырга;"

1.3. 17-нче маддәнең 1-нче өлешендәге 10-нчы пункт түбәндәге редакциядә бәян итергә:

"10) «Коррупциягә каршы тору турында»гы 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 маддәсенең 4.2 өлешендә каралган мәгълүматны — әлеге затта «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүенә контрольлек итү турында»гы 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүмат бирү өчен нигезләр барлыкка килгән очракта — тапшырырга; керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы әлеге мәгълүмат мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соңгы елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш;"

1.4. 18-нче маддәнең 1-нче өлеше 2-нче пунктының (а)–(с) пунктчалары түбәндәге редакциядә бәян итергә:

а) сәяси партия яки һөнәри берлек органы (шул исәптән җирле үзидарә органы каршындагы башлангыч һөнәри берлек оешмасының сайлап куела торган органы)

эшендә түләүсез нигездә катнашу, яисә башка иҗтимагый берләшмә, торак кооперативы, торак төзелеше кооперативы, гараж кооперативы яки күчемсез милек хуҗалары берләшмәсенең корылтаенда (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә бушлай нигездә катнашу (сәяси партия яки һөнәри берлек органы — шул исәптән җирле үзидарә органы каршындагы башлангыч һөнәри берлек оешмасының сайлап куела торган органы — белән идарә итүдә, яисә башка иҗтимагый берләшмә, торак кооперативы, торак-төзелеш кооперативы, гараж кооперативы яки күчемсез милек хуҗалары берләшмәсенең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашуны исәпкә алмаганда), моның өчен әлеге субъектның законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазифаи затына алдан хәбәр итү шарты белән;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләр советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә һәм аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен бушлай нигездә тәкъдим итү;”;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Бу карарның үтәлешен күзәтү хокукын үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
Районы Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р. Т. Галәветдинова